КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 27 гыйнвар г.Казань № 29

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмалары студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләрне гамәлгә кую турында» 2016 ел, 20 сентябрь, 660 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмаларының педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча укучы студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләр бирү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмалары студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләрне гамәлгә кую турында» 2016 ел, 20 сентябрь, 660 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 10 май, 338 нче; 2020 ел, 2 октябрь, 901 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмаларының педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең

мәгариф программалары буенча укучы студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләр бирү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Стипендияләр алган беренче һәм аннан соңгы курслар студентларына стипендия билгеләү алдыннан уздырылган беренче һәм аннан соңгы арадаш аттестацияләр йомгаклары буенча «канәгатьләнерлек» бәяләү булмаганда түләнә.»;

5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«салым органының стипендия билгеләргә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1нче көне хәленә карата салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмауны раслый торган белешмә кәгазе.»;

13 пунктның бишенче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Аннан соңгы арадаш аттестацияләр йомгаклары әлеге Кагыйдәләрнең 4 пунктында билгеләнгән йомгакларга туры килгәндә, студент стипендия алуга дәгъва итәргә хокуклы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин